# Әниләрдә безнең юл башы

**Әлфия Аксуева**
Яр Чаллы шәһәренең 12 нче китапханәсе

**1 алып баручы:** Туарына бер көн кала сабый Аллаһы Тәгаләдән сорый икән:
– Ул дөньяга мин ник киләм?
– Мин сиңа фәрештә җибәрәм, ул сиңа барысын да аңлатыр.
– Ә мин аны ничек аңлармын соң?
– Ул сине үз теленә өйрәтер.
– Фәрештәмнең исеме ничек була?
– Син аңа Әни диячәксең.

**2 алып баручы:** Кайдан башлана хатын-кыз?
Яз ачкан бөреденме,
Чәчәкләре серкәләнеп
Җимешен күрүденме?
Кайдан башлана хатын-кыз?
Әнилектән башлана!
Өмет чәчә ак дөньяга,
Гомер җебе - тантана!

**1 алып баручы:** Хөрмәтле укучылар, укытучылар, кунаклар! Һәр елда ноябрьнең соңгы якшәмбесендә бәйрәм ителүче Әниләр көненә багышланган кичәбезне башлап җибәрәбез. Әниләр көне 1998 елның 30 гыйнварында Россия Президенты Борис Ельцин кул куйган Указ нигезендә билгеләп үтелә.

**Укучы:** Кем өчен дә иң беренче әни кирәк,
Юктыр җирдә әниләрдән кадерлерәк.
Егылсак та, еласак та, әни кирәк.
Шатлыкта да, кайгыда да безгә терәк.
Әни назы, әни сүзе сеңсә күбрәк,
Абынулар, ялгышулар була сирәк.
Олыга да, кечегә дә әни кирәк.
Әни булса, яшәүләре җиңелерәк.
Исән чакта кадерләрен белик күбрәк.
Игелекле, иң изге зат – Әни кирәк.
(«Әни кирәк». Идият Әширов шигыре)

**2 алып баручы:** Әнкәй, әни, нәнә, инәй, әсәй... Сиңа балаларың нинди генә исемнәр белән эндәшмәсен, эчтәлегең бер үк кала. Ана! Күкрәк сөтен имезеп үстергән, төннәрен, йөрәк җимешләре өчен борчылып, бер генә мизгелгә дә керфек какмаган Ана. Никадәр сабырлык, дөньядагы никадәр матурлык, мәхәббәт һәм күңел киңлеге синдә.

**1 алып баручы:** Ана белән бала! Бер-берсенә алардан да якын җан иячәрен табып буламы икән бу дөньяда?! Ана кешегә нәсел, милләт, кешелекне дәвам иттерү, яшь буын тәрбияләү кебек олы вазифа йөкләнгән.

**2 алып баручы:** Туасы сабыйны һәр өйдә зур түземсезлек, олы өметләр белән көтеп алалар. Яңа туган бала гаиләне ныгыта. Яшь балалы йортка нур иңә, анда тормыш кайный, гайбәт сүз, ызгыш-талашка урын калмый, ди халык.

**1 алып баручы:** Башка халыклардагы шикелле үк, татарларда да бәби тууга бәйле йола һәм гадәтләр байтак. Әлеге йолаларның нигезендә ана һәм баланың саулыгын, баланың киләчәк тормышын, уңышларын, бәхетле гаилә коруын кайгыртуга корылган кузаллаулар ята.

**2 алып баручы:** Дөньяга килүнең беренче кырык көнен, беренче атнасын барлык халыклар да үзенчә билгеләп үтә. Нәкъ шушы көннәрдә баланы карау мәшәкатьле дә, мавыктыргыч та бер төс ала, аны яман күзләрдән-көчләрдән саклау өчен бөтен йолалар да җиренә җиткереп үткәрелә. Кырык көн дәвамында бала тапкан әни кеше үзе дә, аның сабые да күз өстендәге кашка әйләнә, аларны һәрдаим кайгыртып, алар өчен борчылып торалар.

**1 алып баручы:** Теге яки бу гаиләдә бәби туса, яшь ананың хәлен белергә, аны котларга килү, саулыгын кайгырту якын кешеләре өчен язылмаган бер бурыч булып тора. Хәл белергә берәү дә буш кул белән килми. Һичшиксез, сый-нигъмәт белән килә, әлеге йола «Бәбәй ашы», «Бәбәй туе», «Бәби чәе», «Бәби боткасы» дип атала.

Күз тия дип борчылганга, баланы кырыгына кадәр чит кеше күзенә күрсәтергә атлыгып тормыйлар, күрсәтмиләр дә.

**Укучы:** Яңа бәби алып кайтты
Әни базардан.
Күрше-күлән кереп тулды
Бәби карарга.
Кергәннәргә күрсәтәләр
Бары тәпиен.
Юкса күз тидерәсез, дип
Көлә әбием.
Дәү үссен дә таза булсын,
Бик матур, имеш.
Мактаган булалар тагын,
Күрмәгән килеш.
Ничек итсәм иттем әле,
Хәйләсен таптым:

Кеше югында биләвен
Чиштем дә бактым.
Шаккатмалы икән чынлап,
Нәни аяк-кул,
Бәбиебез сокланырлык
Матур икән шул!
(«Яңа бәби». Эльмира Шәрифуллина шигыре)

**2 алып баручы:** Татарда «бәби мунчасы» дип аталган бик күркәм бер йола яшәп килә. Элек бәби коендырырга кендек әбисен чакырганнар. Ә ул инде бәби коендыруның бөтен нечкәлекләрен белгән, бу эшкә бик җаваплы караган. Коендырганда учлары белән сыйпап сабыйның башын «йомрылаган», гәүдәсе буйлап кулларын йөртеп буен «үстергән», кул-аяк бармакларын ышкыган, колакларын, күзләрен, борынын, авызын юган.

**1 алып баручы:** Кагыйдә буларак, хәзер бәбине әни кеше үзе яисә аның әбисе юындыра. Бала коендырганда бик күп матур теләкләр әйтелә. Аларның бер өлеше сәламәтлек, озын гомер, бәхет теләсә, икенче өлеше-тәүфикъ, олысы-кечесенә ихтирамлы булуны тели. Мәсәлән, «Бисмиллаһ иррахмән иррахим, суы сарыксын, үзе калыксын! Чыршыдай озын, нараттай кызыл, имәндәй таза, каендай зифа булсын! Әтиле-әниле булсын, тигез канатлы булсын, олыларны олы итсен, кечеләрне кече итсен, бәхетле булсын, тәүфыйкълы булсын!»

**2 алып баручы:** Бәби коендырган беренче көннәрдә күршеләрне, туганнарны, танышбелешне дә мунчага дәшәләр. Мондый чакыруны һәркем сөенеп кабул итә, чөнки бәби мунчасы гөнаһлардан, авырулардан арындыра дип санала.

**1 алып баручы:** Бәби туганнан соң үткәрелә торган йолалар арасында «исем кушу» йоласы аерым бер игътибарга лаек. Татарларда яңа туган баланы озаклап исемсез тоту куркыныч санала, балага беренче көннәрдә үк ничек тә исем кушарга омтылалар. Бүген татарларда исем кушу йоласы, ислам динен тотучы башка төрки халыклардагы шикелле үк, бер үк канунга нигезләнеп башкарыла. Мендәрдә яткан сабыйны, башын кыйблага каратып, өстәл өстенә куялар. Мулла «Аллаһу әкбәр!» дип өч тапкыр азан әйтә, аннан, баланың башта уң, аннан сул колагына иелеп, әкрен генә аның исемен кабатлый.

**Укучы:** Бала туа. Сабый туганчы ук,
Әти-әни исем сайлыйлар.
Әби-бабай, туган-тумача да-
Һичберсе дә читтә калмыйлар.
Чын безнеңчә, үзебезчә итеп,
Кушсак иде милли исемнәр:
Зөләйхалар, Рәйхан, Минтимерләр,
Маһинурлар, Саимә, Гөлсемнәр.
Атам кушкан изге бүләк - исем,
Милли йөзнең алтын ачкычы.
Шәҗәрәдә нәселләрнең җебе,
Буыннарның сынмас баскычы.
Нурын сибеп торсын исемебез,
Татарлыкны горур яңгыратып.
Яшик әле бердәм, тату булып,
Татар телен сөеп-яратып!
(«Нурын сибеп торсын исемебез». Ирина Хәмидуллина шигыре)

**1 алып баручы:** Бишек тугыз ай буе ана карынында булып, яңа гына якты дөньяга аваз салган бала өчен беренче җылы һәм аулак куыш. Бишек, яңа туган баланы саклап, аның өчен үзенчәлекле «йорт эчендәге йорт» булып тора, ябык һәм яшерен булуы белән ул ана карынын хәтерләтә. Татар халык әйтемнәре шуңа ишарәли: «Бишек-ярты ана», «Бишек-ярты әнкә», «Бишек-назлы ана». Бишекнең әлеге сыйфатлары балага әле аңа бөтенләй дә таныш булмаган дөньяга җайлы гына, салмак кына күчәргә ярдәм итә.

**2 алып баручы:** Бала үскәч, бишекне чормага менгереп җыеп куйганнар, ул анда икенче бала туганны көткән. Кагыйдә буларак, бер бишектә берничә буын балалар үскән. Бишеккә нәни матрас, юрган, мендәр куелган. Элек алар төрле чуар тукымадан, хәтта тукыма кисәкләреннән тегелгән (корама юрган, корама мендәр). Бу чуарлык баланы күз тиюдән саклый дип ышанганнар, янәсе, чит кешенең күзләре беренче булып шуңа төшә һәм бәбигә күз тими. Бишек чаршау, чыбылдык белән капланган - ул баланы тышкы дөньядан саклап торган: артык яктылыкны да, шау-шуны да, чит күзләрне дә кертмәгән.

**1алып баручы:** Бишек төрлечә ясалган: талчыбыктан үрелгән (талбишек), юкә кабыгыннан (кабык бишек), агачтан эшләнгән (такта бишек). Такта бишекләр чыдамлырак булгач, нигездә алар кулланылган. Хәзер дә татарлар балта осталары ясаган агач бишекләрне злә. Бишек ясала торган агач берничә сыйфаты буенча сайланган. Ул йомшак, сыгылмалы, шул ук вакытта чыдам да булырга тиеш. Шуңа күрә юкә, усак, тал, миләш агачына өстенлек бирелгән. Имән белән нараттан бишек ясау традициясе дә бар, янәсе, андый бишектә үскән бала сәламәт

һәм озын гомерле була. Каен татар кешесе өчен сагыш, хәсрәт, кайгы билгесе булганга, бишекне каеннан ясау катгый тыелган.

**Укучы:** Бездә бишек әллә ничек-
Талдан, җирдан үреләә.
Җырлы бишек, җылы бишек
Эленә өй түренә.
Җырлый бишек, елый бишек!
Җырлый-елый, моңлана-
Әллә бишек, әллә инде
Бишектә яткан бала?!
Бишеге дә үрелгән шул
Сөндә үскән таллардан-
Җырчы таллар, елак таллар...
Моңнар тама алардан.
Ул талларга ал таңнарда
Сандугачлар кунгандыр.
Кунып кына калмагандыр,
Оя корган булгандыр.
Сеңгәндер ул талбишеккә
Әнкәмнең моңнары да.
Шулайдыр шул, талбишекнең
Юк шуңа тынганы да.
(«Талбишек». Роберт Миңнуллин шигыре)

**2 алып баручы:** Элек татарларда сиртмәле бишек киң таралган була. Андый бишек бер яки ике борыслы кысадан торган. Аскы борыска киндер тарттырылган, өскесенә нык баулар бәйләнеп, алар озын колга очында - сиртмәдә тоташтырыла, аның бер очы түшәмгә терәлә, икенчесе аска төшә. Әлеге колга ярдәмендә бишек аска - өскә тирбәлә. Татарлар нәкъ менә шулай тирбәтүне дөрес, өскә - аска тирбәтү баланы тиз үстерә, сәламәтлегенә һәм җитлегүенә уңай тәэсир итә дип санаган. Шулай тирбәтүнең зарурлыгы татар халкының фольклор әсәрләрендә - табышмакларда да әйтелә:
Төшә-төшә, җиргә җитми,
Менә-менә, күккә җитми.

**1 алып баручы:** Тора-бара сиртмәле бишекләр пружинага эленгән бишекләр белән алмаштырылган. Андый бишек түшәмгә кагылган ыргакка беркетелгән. Ыргакны матчага беркетергә киңәш ителми. Янәсе, җенле урын булып, саташтырырга мөмкин, шунлыктан матча астында йокламыйлар, бәбине дә салмыйлар. Бәби йә кыйблага карап, йә аңа аркасын куеп ятарга тиеш, башка яклар дөрес түгел дип саналган.

**2 алып баручы:** Гомеренең беренче көннәреннән үк бала бишек җырлары аша үз халкының мәдәнияте белән таныша - туган телен, көен ишетә, көнкүреш үзенчәлекләрен белә, тирәлекне таный, якын кешеләрнең хисләрен аңларга өйрәнә. Баланы дөнья белән таныштыру йомшак кына, салмак кына бара.

Кичке тынлыкны сакларга,
Салмак кына калка ай.
Бәбиләргә бишекләрдә
Йоклар вакыт, балакай.
Йокла, балам, иртән тагын
Уянырсың, йолдызым.
Инде күктә ай калыккан,
Күзләреңне йом, кызым.

**1 алып баручы:** Бишек җырын, кагыйдә буларак, балага әнисе җырлавы әһәмияткә ия, чөнки тормышның бу этабында бала өчен ана дөньяның зур бер өлешен тәшкил итә. Бишек җырларының төп функциясе – бәбине бишек тирбәлешенә туры килгән салмак кына ритм һәм монотон көй белән тирбәтеп йоклату.

Экранда видеоклип күрсәтелә. Ландыш Фазуллина. Бишек җыры

**2 алып баручы:** Бишек җыры көйли-көйли ана гадидән катлаулыга, якыннан еракка күчә, кечкенә кешенең башына зур дөнья турында беренче гыйлемнәрне сала.

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу.
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып китәр бу.
Әлли-бәлли ит, балам,
Сине бишеккә салам.
Сине бишеккә салгач та,
Үзем эшемә барам.

**1алып баручы:** Ана ихластан башкарылган бишек җырларына үз хисләрен, теләкләрен һәм баланың киләчәгенә бәйле борчуларын сала.

Әлли-бәлли-бәү, бәү,
И җомырым, җомырым,
Саулык-сәламәтлек белән
Озын булсын гомерең.
Йокла, кызым, йокла, кызым,
Йокла, кызым, йом күзең.
Үсеп матур кыз булган соң,
Кияү табарсың үзең.
Улым, улым, ул кеше,
Улыма кирәк кыз кеше.
Кода булып йөрүләрне
Булдыра алмый күп кеше.

**2 алып баручы:** Бала туугa бәйле йола - гадәтләрне барлап чыккач, бер нәрсәгә инанасың: еллар,

гасырлар дәвамында аларның байтагы онытылган, югалган, үзгәреш кичереп, башка төсмер алган. Әмма асылы шул ук калган. Шунысы сөенечле: сабыйның беренче көннәреннән үк аңа үзгә бер игътибар күрсәтү, туган-тумачаның моны уртак бәйрәм буларак кабул итүе, үзара ярдәмләшеп, кунакларга йөрешеп аралашуы, өлкәннәргә ихтирамлы мөнәсәбәт татар халкы өчен бүген дә җуелмас рухи кыйммәтләрнең берсе булып кала.

**1 алып баручы:** «Оҗмах – аналарның аяк астында» диелә хәдистә, ул оҗмах капкалары һәркемгә дә ачык, әниләренең кадерен белгән, хөрмәт иткән һәм аларның фидакарь хезмәте һәм чиксез сөюләренә тиешле бәя биргәннәрнең барысына да ачык ул ишек.

Бүгенге чарада катнашучылар арасында әниләр дә бар. Хөрмәтле әниләр!

Сезне чын күңелдән күркәм бәйрәм - Әниләр көне белән тәбрик итәбез. Сезнең һәркайсыгызга ныклы сәламәтлек, бәрәкәтле озын гомер, ак бәхетләр, гаиләләрегезгә иминлек телибез.

**2 алып баручы:** Газиз балаларыгызның игелеген күреп, яраткан әни һәм әби булып, шатланып – куанып яшәүләр насыйп булсын!

Киләсе очрашуларга кадәр сау булыгыз!

Библиография:

Әширов И. Әни кирәк/Идият Әширов//Курамшин Р.С. Балачак бәйрәмнәре.-Казан: Татар. кит. нәшр., 2014.-Б.65-66.

Брусько, З. «Әлли-бәлли, бәлли-бәү...»/Зәлия Брусько//Түгәрәк уен.-2021.-№3.-Б.26-29.

Брусько, З. Бәби мунчасы саваплы була: татарларның бала коендыру йоласы/Зәлия Брусько//Түгәрәк уен.-2020.-№3.-Б.22-24.

Брусько, З. «Җырлы бишек, җылы бишек эленә өй түренә»/Зәлия Брусько//Түгәрәк уен.-2021.-№4.-Б.14-19.

Дәүләтшина, Л.Х. Сөннәт йоласы/Ләйлә Дәүләтшина//Түгәрәк уен.-2018.-№4.-Б.13-15.

Хәмидуллина. И. Нурын сибеп торсын исемебез/ Ирина Хәмидуллина// Түгәрәк уен.-2021.-№2.-Б.58.

Шәрифуллина, Э.М. Эльмира Шәрифуллина: балалар өчен шигырьләр, җырлар, сценарийлар, әкиятләр, хикәяләр, табышмаклар/Эльмира Шәрифуллина.-Казан:Татар.кит.нәшр., 2014.-303 б.